КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 8 июль г.Казань № 657

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Татарстан Республикасының Сарман муниципаль районында «Зәй – Сарман» – Сәвекле фермасы төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында «Зәй – Сарман» – Сәвекле фермасы автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән барлыкка килә торган, «ЭНЕРГИЯ» җир корпорациясе» акционерлык җәмгыяте (алга таба – җир кишәрлекләре милекчесе) милкендә булган, 34 182 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен җир кишәрлекләре милекчесенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләре өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аларны алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә җибәрүне;

килешүләр төзүне;

җир кишәрлекләре өчен акча түләүне;

җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

җир кишәрлекләре милекчесе тарафыннан имза куелган килешүләр законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында «Зәй – Сарман» – Сәвекле фермасы автомобиль юлын төзү» объекты территориясен планлаштыру документларын раслау турында» 2016 елның 1 декабрендәге 508 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин